**СОВЕТ ЛАИШЕВСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**

422610 г.Лаишево,
ул. Первомайская, д.39
тел: (8-84378) 2-51-51
факс: (8-84378) 2-55-55

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЛАЕШ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОН СОВЕТЫ**

422610 Лаеш ш.,
Беренче май урамы, 39 нчы йорт,
тел: (8-84378) 2-51-51
факс: (8-84378) 2-55-55

**2023елның 31 июле** **77-РС номер**

# КАРАР

## Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Сокуры авыл җирлегенең Генераль планына үзгәрешләр кертү Проектын раслау турында

Россия Федерациясе Шәһәр төзелеше кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Уставы нигезендә, Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Сокуры авыл җирлегенең 2023 елның 05 июлендәге 10-53/8076 номерлы генераль планына үзгәрешләр кертү проектына бәяләмәсен, 2023 елның 12 июлендәге ачык тыңлаулар нәтиҗәләре турында бәяләмәне карап чыгып, Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Советы **карар чыгарды:**

1. Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Советының 2012 елның 16 октябрендәге 67-РС карары белән расланган Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының Сокуры авыл җирлеге генераль планына (1 нче кушымта) үзгәрешләр кертү проектын расларга.
2. Әлеге карарны “Кама ягы”(«Камская новь») район газетасында, Интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында http://pravo.tatarstan.ru. веб–адресы буенча һәм интернет телекоммуникация челтәрендәге Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре Порталында урнаштырылган Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районының рәсми сайтында- http://laishevo.tatarstan.ru. веб-адресы буенча бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).
3. Әлеге карар рәсми басылып чыккан (игълан ителгән) көненнән үз көченә керә.
4. Әлеге Карарның үтәлешен тикшереп тору Татарстан Республикасы Лаеш муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең инфраструктур үсеш буенча урынбасары И.П. Шитовка йөкләнә.

**Башлык – муниципаль район**
**Советы Рәисе** **И.Ф. Зарипов**